| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.02.2020 Казан ш. № 61-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
03.02.2020 № 61-пр
карары белән расланды

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым
боерыкларына кертелгән үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 28.10.2019 № 556-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмага дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы»;

4 нче кушымтадагы Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчеләр тарафыннан өстәмә тапшырыла торган документлар исемлегендә 4 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшкә алу турында боерык, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яисә яисә, Россия Федерациясенең Хезмәт Кодексы яки башка федераль закон нигезендә гражданинның хезмәт кенәгәсе алып барылмаса, Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында каралган тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә, яки хезмәт шартнамәсе (контракт).»;

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 01.11.2019 № 570-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яисә

юридик затларга сатулашулар уздырмыйча арендага яисә милек итеп бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмага дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы»;

8 нче кушымтаны яңа $36^1$ пункты белән тулыландырырга:

«$36^1$) җир кишәрлеген товар аквакультурасы (товар балыкчылыгы) эшчәнлеге алып баручы затка күрсәтелгән максатларда дәүләти яки муниципаль милек булган балыкчылык участогын файдалану шартнамәсе нигезендә (алга таба - балыкчылык участогын файдалану шартнамәсе);»;

9 нчы кушымтаның алтынчы «Гариза бирүченең җир кишәрлегенә сатулашулар уздырмыйча ия булу хокукын раслаучы һәм җир кишәрлегенә хокукка ия булу турында гаризага теркәлә торган документлар» баганасында җир кишәрлегенә сатулашулар уздырмыйча ия булу хокукын раслаучы Документлар исемлегенең 15 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшкә алу турында боерык, хезмәт кенәгәсеннән өземтә яисә яисә, Россия Федерациясенең Хезмәт Кодексы яки башка федераль закон нигезендә гражданинның хезмәт кенәгәсе алып барылмаса, Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында каралган тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә, яки хезмәт шартнамәсе (контракт)

* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлеге турында) ЕГРНнан өземтә».